Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Борискино авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

15 ноябрь 2022 ел №18

Әлмәт муниципаль районы Борискино авылы башкарма комитетының 2013 елның 10 сентябрендәге 5 номерлы «Терроручылыкны һәм экстремизмны, наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру, шулай ук аларның чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерү (яисә) ликвидацияләү турында»гы карарын гамәлдән чыгару хакында

Хокукый мониторинг тәртибендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2022 елның 27 октябрендәге 02-08-02/374-2022 номерлы протестын карап,

Борискино авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Борискино авылы башкарма комитетының 2013 елның 10 сентябрендәге 5 номерлы «Террорчылыкны һәм экстремизмны, наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру, шулай ук аларның чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) ликвидацияләү турында»гы карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны Борискино авылы, Үзәк ур., 61 йорт, Березовка бистәсе, Үзәк урам, 16 йорт торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Борискино авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Ж.С.Илалов